| Республика Татарстан<br>Совет Большенуркеевского<br>сельского поселения<br>Сармановского<br>муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль<br>районының Зур Нөркәй<br>авыл җирлеге<br>Советы |
|---|---|

---

| **РЕШЕНИЕ**<br>2024 елнын 22 ноябре | **КАРАР**<br>№ 105 |
|---|---|

«Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына социаль-икътисади үсеш фаразы турында»

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставы нигезендә, Башкарма комитет житәкчесенең «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл жирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразы турында»докладын тыңлаганнан һәм фикер алышкач, Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл жирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. "2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше фаразы турында» мәгълүматны игътибарга алырга (1 нче кушымта).

2. Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитетына 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл жирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразын үтәүне тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольне Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл жирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге
Совет рәисе урынбасары  Х.Ш.Шайхеразиев

Кушымта 1

**Сарман муниципаль районы**
**Зур Нөркәй авыл җирлегенең**
**2025 елга һәм 2026-2027 елларга**
**социаль-икътисади үсеш фаразы**

| Күрсәткечнең исеме | Үлчәү берәмлеге | 2022 хисап | 2023 хисап | 2024 билге | 2025 прогноз | 2026 прогноз | 2027 прогноз |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Халык саны | кеше | 530 | 510 | 520 | 520 | 520 | 530 |
| Узган ел белән үсеш темплары | % | | | | | | |
| Терлекләр саны | баш | 250 | 255 | 250 | 250 | 250 | 250 |
| Узган ел белән үсеш темплары | % | | | | | | |
| Инвестицияләр | мең сум | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 |
| Узган ел белән үсеш темплары | % | | | | | | |
| Торакны файдалануга тапшыру | кв.м. | 0 | 100 | 100 | 0 | 100 | 0 |
| Узган ел белән үсеш темплары | % | | | | | | |
| Хезмәт хакы фонды | мең сум | 36080.7 | 44920,5 | 50805,1 | 55834,8 | 61139,1 | 67069,6 |
| Узган ел белән үсеш темплары | % | | | | | | |
| Уртача айлык хезмәт хакы | сум | 42953,2 | 53476,8 | 60482,3 | 66470,0 | 72784,6 | 79844,8 |
| Хезмәткәрләрнең уртача саны | кеше | 95 | 95 | 95 | 95 | 95 | 95 |
| Эшмәкәрләр саны | кеше | 10 | 11 | 12 | 12 | 12 | 12 |
| Эшсезләр саны | кеше | 2 | - | - | - | - | - |

Зур Нөркәй авыл җирлеге хисапчысы ____________ Шайхутдинова Г.Н.

**Сарман муниципаль районы**
**Зур Нөркәй авыл җирлегенең**
**2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар**
**план чорына социаль-икътисади**
**үсеш фаразына аңлатма**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы керем чыганакларын һәм бюджет чыгымнары маддәләрен формалаштыру өчен кирәкле төп макроикътисади күрсәткечләрне үз эченә ала.

Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең 2025-2027 елларга социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән 2025-2027 елларга Россия Федерациясе икътисадының сценарий шартларының база варианты нигезендә эшләнде, 2024 елда көтелгән нәтиҗәләр бәясен исәпкә алып, Зур Нөркәй авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсешенә анализ ясалды. 2025-2027 елларда Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2025-2027 елларга тәкъдим ителгән инфляция күрсәткечләрен һәм дефлятор индексларын кулланып, икътисад һәм социаль өлкә үсеше тенденцияләре.

Фаразда түбәндәге тенденцияләр исәпкә алынган: 2024 елнын язында фаразлана торган дәрәҗә белән чагыштырганда нефтькә дөньякүләм бәяләрнең югарырак дәрәҗәсе; чит ил валюталарына карата рубльнең көчсезләнүе; хезмәт базарында кадрлар өчен конкуренция һәм шуның белән бәйле рәвештә хезмәт хакларының һәм халыкның акча керемнәренең үсеше; югары инвестиция активлыгының саклануы; эшкәртү сәнәгатен чыгаруның алдан үсүе, нигездә эчке ихтыяжга (куллануучылар ихтыяжына да, инвестиция ихтыяҗына да) йөз тоткан тармаклар хисабына. Фаразны эшләгәндә Россия Федерациясе Президентының «2030 елга кадәр чорга һәм перспективада 2036 елга кадәр Россия Федерациясе үсешенең милли максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы Указы (алга таба – 309 номерлы Указ) белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә һәм бурычларга ирешү һәм яңа милли проектларны гамәлгә ашыру зарурлыгы исәпкә алынды.

Зур Нөркәй авыл җирлеге 1 торак пункттан тора: Зур Нөркәй авылы.

2024 елга Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегендә халык саны – 520 кеше, 2025 елга – 520 кеше, 2026 елга 520 кеше тәшкил итәчәк.

Авыл хуҗалыгын үстерү фаразы «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖнең «Агрокөч төркеме» ЯАҖнең булган потенциалын һәм үсеш тенденцияләрен, фермер һәм шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, шулай ук «АПКны үстерү» һәм «шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү»программаларын тормышка ашыру буенча билгеләнгән чараларны исәпкә алып эшләнде.

Хәзерге вакытта авыл җирлеге территориясендә «Нөркәй» агрофирмасы ҖЧҖ «АГРОКӨЧ ТӨРКЕМЕ» ЯАҖ һәм «ГранаТ-Стан Групп»ААҖ эшчәнлеге алып барыла.

2024-2027 елларда 200 кв.метр тирәсе торакны файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2024 елда хезмәт хакы фонды 50805,1 мең сум тәшкил итәчәк.

Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны 95 кеше тәшкил итә.

2024 елда уртача айлык хезмәт хакы 60482,3 сум тәшкил итәчәк. 2025 елга фаразлар буенча ул 66470,00 сум тәшкил итәчәк, 2026 елда – 72784,6 сум, 2027 елда – 79844,8 сум.

2024 елга исәпләүләр буенча эшмәкәрләр саны 12 кеше тәшкил итәчәк, 2025 елга-12 кеше, 2026 елга-12 кеше.